**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне башкаручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү күләмен арттыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 16 июнендәге ПУ-221 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 28 февралендәге ПУ-117 номерлы, 2008 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы, 2010 елның 9 февралендәге ПУ-48 номерлы һәм 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче хезмәткәрләре вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) указлары нигезендә билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм

Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-491 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-647 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-942 номерлы указлары нигезендә арттырылган (индексацияләнгән) вазыйфаи окладлары күләмен 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттырганда (индексацияләгәндә) аларның күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 11 август
№ ПУ-669